**СОВЕТ КРАСНОСЕЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422700, Республика Татарстан, Высокогорский район, п. ж/д ст. Высокая Гора, ул. Советская, 13

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КРАСНОСЕЛЬСКИЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422700, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Биектау тиемер юл станциясе поселогы, Совет урамы, 13

тел./факс 8(84365) 2-35-82,e-mail: Ksel.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**30 декабрь 2025 ел** **№ 15**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Советының 2019 елның 22 ноябрендәге 148 нче номерлы «Җир салымы турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Советы

**КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Советының 2019 елның 22 ноябрендәге 148 нче номерлы (2020 елның 15 маендагы 164 нче номерлы, 2022 елның 25 ноябрендәге 57 нче номерлы, 2023 елның 13 ноябрендәге 78 нче номерлы, 2023 елның 29 декабрендәге 86 нчы номерлы; 2025 елның 16 апрелендәге 125 нче номерлы Совет карарлары редакциясендә) «Җир салымы турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Красносельский авыл җирлеге Советының 2025 елның 16 апрелендәге 125 нче номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Советының 2019 елның 22 ноябрендәге 148 нче номерлы «Җир салымы турында» карарына үзгәрешләр кертү хакындагы карарында 1.1 пунктның беренче абзацында «2 пунктның 2 пунктчасында» сүзен «2 пунктның 1 пунктчасында» сүзенә алмаштырырга.

1.2. 2 пунктның 1 пунктчасындагы дүртенче абзацта «, һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артыграк булган әлеге абзацта күрсәтелгән җир кишәрлекләреннән тыш» сүзләрен өстәргә.

1.3. 2 пунктның 1 пунктчасының бишенче абзацында «шәхси ярдәмче хуҗалык (йорт яны кишәрлекләре) алып бару өчен» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә законлы көченә керә.

Совет Рәисе,
авыл җирлеге Башлыгы Р.Ф. Хисаметдинов